**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «07» ноябреннән № 322

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма

комитетының «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентынның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерүе мөрәҗәгать итүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов